СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №143 (7442) | 1 декабрь, 1992 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Урманчылар эштә

**Урман промышленносте хуҗалыгы.** Көзге пычраклык, юлсызлык урманчыларның эшенә шактый тоткарлык ясады. Инде һава торышы җайланып, юлларга тотрыклылык иңгәч эшләр акрын гына җайга төшә башлады.

Агач әзерләүчеләр арасында Николай Степанович Суховның 5 кешелек бригадасы һәрвакыттагыча әйбәт нәтиҗәләр бирә. Айдан-айга планнарны үтәп килүче, стабиль нәтиҗәләргә ирешүче коллектив уңышында бригадир Николай Степановичның тырышлыгы зур роль уйный. Тәҗрибәле урман эшчесе кешеләр белән уртак тел таба, коллективны хезмәткә туплый белә.

Инде агач эшкәртүчеләргә килсәк, Бутаиха урман пунктыннан Михаил Григорьевич Лисюков бригадасына тиңнәр юк. Авыр хезмәтне җиренә җиткереп башкаралар, һәрвакыт күркәм нәтиҗәләргә ирешәләр алар.

Урманчылар акрынлап урман ташуны да ритмга салып киләләр. Бу эштә Николай Корсаков һәм Касыйм Усманов эшли торган агрегат алда бара.

Урманчылар хәзер һәр көнне файдага кулланып, елны әйбәт нәтиҗәләр белән тәмамларга омтылып эшлиләр.

**З. ХӘБИБУЛЛИНА,**
план-экономика бүлеге начальнигы.



Алар—шоферлар. Җәйге тузанлы эссе һавада да, көзге пычракта да, кышкы суыкларда да алар руль артына утыралар да юлга чыгалар. Техникага мәхәббәт Анатолий һәм Василийны шул һөнәрне сайларга этәрә, хуҗалык мәшәкатьләре белән яшәргә, һәр нарядны төгәл үтәргә күнегү егетләргә тоткарлыксыз эшләргә көч бирә. Хәер, Анатолий Иванович Гавриловның да, Василий Валентинович Захаровның да әле беләкләреннән көч-куәт, йөрәкләреннән омтылышның ташып торган чагы. Шуңа да «Мамык» совхозының төп яшь эшче кәчләренә хас булганча, хуҗалык экономикасын ныгытуда хезмәтләрен бер дә иренмичә, бик теләп куялар.

РӘСЕМДӘ: «Мамык» совхозы шоферлары А. И. Гаврилов һәм В. В. Захаров.

Н. Азизов фотосы.

## Әйбәт үсеш алалар

«Рассвет» совхозында ит җитештерүгә зур игътибар бирелә. Шунлыктан мөгезле эре терлекләрдән һәрвакыт әйбәт үсеш алына. Агымдагы елның 10 аенда совхоз буенча мөгезле эре терлекләрнең уртача тәүлеклек артымы 555 грамм тәшкил итте. Ул үсешләр тәҗрибәле терлекчеләр тырышлыгы белән яулана. Мәсәлән, Риф Рәшитович Маняпов 2 айдан зуррак булган бозаулар карый. Җәй көне ул аларны җәйләүдә асрый һәм кышларын да ул аларны үзе карый. Ул тәрбияләгән бозаулар көр булып үсәләр, үлем-китем дә юк. Агымдагы елның 10 аенда ул алардан 9 центнер үсеш алды, малларның тәүлеклек уртача артымнары 750 грамм тәшкил итте. Риф Рәшитович шушы тармакта 4 елдан артык хезмәт куя инде. Бу эш аңа бик охшый һәм ул аны теләп башкара. Бозауларны ул физик торышларына карап рацион буенча ашата һәм эчертә. Зооветталәпләр кушканча печән, салам, тоз, минераль өстәмәләр бирә һәм нәтиҗәләре дә шуңа әйбәт. Биредә малларны кышлату өчен барлык шартлар да тудырылган, авыр эшләр механикалаштырылган, маллар өчен яхшы сыйфатлы азык хәзерләнгән.

**В. САТДАРОВ**

## Сессия ачылды

**Татарстан Республикасы Югары Советының уникенче чакырылыш XIII сессиясе 1992 елның 30 ноябрендә сәгать 10да Татарстан Республикасы Югары Советының утырышлар залында ачылды.**

# Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы карары

**Татарстан Республикасының уникенче чакырылыш Югары Советының ундүртенче сессиясе көн тәртибе турында**

Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Югары Советының ундүртенче сессиясе көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
2. «Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
3. 1992—1995 елларга Татарстан Республикасында җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча Дәүләт комплекслы программасы проекты турында.
4. «Милиция турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
5. «Татарстан Республикасында судьяларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
6. «Татарстан Республикасында судлар төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
7. «Юл хәрәкәте, транспортны файдалану һәм саклау, юл-урам челтәрен тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
8. «Хокук һәм җәмәгать тәртибен, идарә итүнең билгеләнгән тәртибен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
9. «Ату коралын һәм хәрби кирәк-ярakларны сатып алу, саклау һәм файдалану кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
10. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
11. «Татарстан Республикасы Прокуратурасы турында»гы Закон проекты хакында.
12. «Татарстан Республикасында Дәүләт яшьләр сәясәте турында»гы Закон проекты хакында.
13. «Җир өчен түләү турында»гы Закон буенча Татарстан Республикасы Президентының тәкъдиме хакында.
14. Республика мөлкәте һәм коммуналь мөлкәт арасында милекне аеру турында.
15. «Күмәк шартнамәләр һәм килешүләр турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.
16. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законы проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. МӨХӘММӘТШИН.**
Казан, 1992 ел, 20 ноябрь.

# Игътибар арта

**Үләннәр орлыкчылыгы станциясе.** Зур булмаган бу коллектив хәзер бер үк вакытта үләннәр орлыгы әзерләү һәм аларны чистарту белән шөгыльләнә. Шунысы куанычлы: соңгы елларда үлән орлыгы үстерү белән шөгыльләнүнең файдалы булуын аңлап, әлеге эшкә алынучыларның саны байтакка артты, бу безгә әзерләү эшләрен уңышлы алып барырга мөмкинлек бирдә. Быел 1 октябрьгә станция 16 миллион 12 мең сумлык үлән орлыгы әзерләде, район буенча бу юнәлештә безнең иң төп ышанычлыларыбыз— «Мамык» һәм «Рассвет» совхозлары. «Мамык» совхозы, мәсәлән, 261 центнер донник орлыгы тапшырды, шуның белән совхоз кассасына 4 миллион 510 сум табыш кертте. Хуҗалык әлеге эшне киләчәктә дә дәвам итәргә җыена. Бу җәһәттән «Рассвет» совхозы үзенең стабильлеге, нәтиҗәле эшләве белән күпләргә үрнәк. Быел алар 283 мең сумлык люцерна, 3 миллион 100 мең сумлык костер орлыгы әзерләп тапшырдылар. Районда оешып килгән фермер хуҗалыклары да бу табышлы тармакка игътибар бирәләр. «Аргамак» хуҗалыгы, мәсәлән, 1 миллион 190 мең сумлык фацелия орлыгы сатты. «Чирмешән» фермер хуҗалыгы исә 436 меңлек костер орлыгы тапшырды.

Хәзер, әйткәнебезчә, станциядә орлыклар эшкәртү алып барыла. Бу хезмәт белән озак еллар инде орлык чистарту эшчеләре Тамара Александровна Григорьева һәм Надежда Александровна Яшмурзина шөгыльләнәләр, аны бар таләпләренә китереп үтиләр. Бу эшне сыйфатлы алып бару баш агроном А. И. Самсоновның даими игътибарында тора. Ә машиналарның төзеклеген К. М. Мөлеков тәэмин итә. Коллектив шулай көйле һәм бердәм эшләп- әйбәт кенә нәтиҗәләргә ирешә.

**В. МАЛИНИНА,**
бухгалтер.

## ЮНЕСКО вәкиле булыр

Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачев 23—24 ноябрьдә Мәскәүдә булганда ЮНЕСКОның Мәскәү бүлеге директоры А. Покровский һәм Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе рәисе А. Жуков белән сөйләшүләр алып барды. Анда әлеге халыкара оешманың программаларында Татарстанны актив катнаштыру, Казан шәһәрендә ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасының милли комитетын ачу мәсьәләләре тикшерелде.

## Ишеттегезме әле...

Красноярскида хосусыйлаштыру чеклары бирү пунктларының берсенә билгесез өч кеше килеп керә һәм газ баллоннары ярдәмендә бөтен бүлмәгә газ сиптерә. Пункт хезмәткәрләре «аңга килгәнче» алар 112 ваучерны эләктереп китәләр, герблы мөһерне дә алырга онытмыйлар. Дөрес, караклар ерак китә алмый, милиция икесен бик тиз тота. Берсен эзләү дәвам итә.

## Игътибар: „Туры элемтә“

**1992 елның 4 декабрендә көндезге 15 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр район эчке эшләр бүлеге район халкы белән «Туры элемтә» үткәрә. Элемтә өчен телефоннар: 2—12—30, 2—12—33, 2—18—47.**

**Шалтыратыгыз, көтәбез!**
**РАЙОН ЭЧКЕ ЭШЛӘР БҮЛЕГЕ.**

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**СИШӘМБЕ**
**1 ДЕКАБРЬ**

**ТАТАРСТАН КАНАЛЫ**

7.00—8.00 «Чулпан». Информацион-музыкаль программа.
18.50 «Хәрәкәт иминлеге өчен».
19.00 Татарстан.
19.30 «СПИД— гасыр проблемасы».
19.50 Әлли-бәлли-бәү.
20.00 «Борынгы татар халык җырлары». Лена Бичарина башкара.
20.15 Кинореклама.
20.20 Тапшырулар программасы.

**ОСТАНКИНО КАНАЛЫ**

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 «Жозеф Бальзамо». Нәфис фильм. 1 нче серия.
10.20 «Футбол күзәтү».
10.50 Мультфильм.
11.30 «Тормыш ваклыклары». 9 нчы серия.
12.20 «Шерлок Холмс һәм доктор Ватсон маҗаралары». 1 нче серия.
13.25 «Телеграмма». Нәфис фильм.
13.55 «Хатыннарны саклагыз» Нәфис фильм. 1 нче серия.
15.25 «Эшлекле хәбәр».
15.40 «Блокнот».
15.45 «Рус музыкасы сәхифәләреннән».
16.15 Мультфильм.
17.05 «Безнең музыкаль клуб».
17.50 Пресс-экспресс.
18.00 Яңалыклар.
18.20 «Яшәүгә хокук».
19.00 «Жозеф Бальзамо». Нәфис фильм.1 нче серия.
20.00 Тема.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 «Тәвәккәллек группасы». Нәфис фильм. 1 нче серия.
22.45 «Хәрби ревю».
23.20 Документаль фильм.
00.00 Яңалыклар.
00.25 А. Скрябин. Өченче симфония. «Илаһи поэма».

**«РОССИЯ» КАНАЛЫ**

8.00 Хәбәрләр.
8.20 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 «Ретушьсыз».
9.55 Россия Федерациясе халык депутатларының VII съезды ачылу.
12.00 «Улочка». Нәфис фильм.
13.20 Мультфильм.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
16.00 Телебиржа.
16.30 «Тылсымлы лампа янында».
17.00 Яңалыклар.
18.00 «Раскол булмас».
18.15 Телекүпер. Санкт-Петербург—Вашингтон.
20.25 «Санта Барбара».
21.15 «Могиканнар». Лев Додин.
21.55 Съезд эше турында отчет.
00.35 «Ихтирамлы булыйк». Режиссер Николай Акимов.

**ЧӘРШӘМБЕ**
**2 ДЕКАБРЬ**

**ТАТАРСТАН КАНАЛЫ**

7.00—8.00 «Чулпан». Информацион-музыкаль программа.
18.40 «Шигърият». Флера Гыйззәтуллина.
19.00 Татарстан.
19.30 Реклама курьеры.
19.35 «Түгәрәк өстәл». Бөтендөнья инвалидлар көненә карата.
20.15 «Әлли-бәлли-бәү».
20.20 Тапшырулар программасы.

**ОСТАНКИНО КАНАЛЫ**

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 «Жозеф Бальзамо». Нәфис фильм. 2 нче серия.
10.20 «Безнең музыкаль клуб».
11.00 Мультфильмнар.
11.30 «Россиядән хат». Документаль фильм.
12.20 Шерлок Холмс һәм доктор Ватсон маҗаралары». 2 нче серия.
13.25 «Күзеңне йом». Нәфис фильм.
13.55 «Хатыннарны саклагыз». Нәфис фильм. 2 нче серия.
15.25 Телемикст.
16.10 «Блокнот».
16.15 Мультфильм.
17.05 «Безнең арада, кызлар арасында».
17.50 Пресс-экспресс.
18.00 Яңалыклар.
18.25 «Останкино» тәкъдим итә.
19.00 «Жозеф Бальзамо». 2 нче серия.
20.05 «Театрда очрашулар».
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 «Тәвәккәллек группасы». 2 нче серия.
22.45 «Кара ящик».
23.15 «М. Магомаев кунакта».
00.00 Яңалыклар.

**«РОССИЯ» КАНАЛЫ**

8.00 Хәбәрләр.
8.20 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 Док. фильм.
9.45 «Параллельләр».
10.00 «Ихтирамлы булыйк». Режиссер Николай Акимов.
10.30 «Коллекционер».
10.45 «Ак карга».
12.00 «Профессор Доэльның васыяте». Нәфис фильм.
13.35 Тинко.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
16.00 «Бизнес: яңа исемнәр».
16.15 «Бадабоки».
16.35 «Беренче тайм».
16.50 Яңалыклар.
17.05 «Ерак Көнчыгыш».
17.50 Христиан программасы.
18.20 Съезд көндәлеге.
18.35 «Кар—язмышым минем». 1 нче серия.
20.25 «Санта Барбара».
21.15 «Ат». Өлкәннәр өчен мультфильм.
21.25 «Ляпсус».
21.50 «ЭКС» программасы.
22.00 Съезд эше турында отчет.
23.00 Хәбәрләр.
23.25 Спорт каруселе.
23.30 Съезд эше турынла отчет.

**ПӘНҖЕШӘМБЕ**
**3 ДЕКАБРЬ**

**ТАТАРСТАН КАНАЛЫ**

7.00—8.00 «Чулпан». Информацион-музыкаль программа.
18.50 Мультфильм.
19.00 Татарстан.



19.30 «Ничек яшисең: театр». Казан дәүләт татар яшьләр театры.
20.15 Әлли-бәлли-бәү.
20.20 Тапшырулар программасы.

**ОСТАНКИНО КАНАЛЫ**

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 «Жозеф Бальзамо». 3 нче серия.
10.25 Г. Беседина җырлый.
10.40 Мультфильм.
11.00 «Талантлар һәм аңа баш иючеләр».
12.20 «Шерлок Холмс һәм доктор Ватсон маҗаралары». 3 нче серия.
13.20 Нәфис фильм.
15.25 Телемикст.
16.10 Блокнот.
16.15 Мультфильм.
17.20 «Шәфкатьлелеккә хокук».
17.50 Пресс-экспресс.
18.00 Яңалыклар.
18.15 «...уналтыга кадәр һәм өлкәнрәкләргә».
19.00 «Жозеф Бальзамо». 3 нче серия.
20.05 Россиядә Букер әдәбият премиясе.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 «Миллион» лоттосы.
22.10 «Тәвәккәллек группасы». 3 нче серия.
23.15 А. Эйзен борынгы рус романсларын җырлый.
23.25 «Максима».
00.00 Яңалыклар.

**«РОССИЯ» КАНАЛЫ**

8.00 Хәбәрләр.
8.20 Эшлекле кешеләр заманы.
8.55 «Монстр». 7 нче фильм.
9.50 «Өй клубы».
10.05 «Абзац».
10.35 «Джентльмен-шоу».
11.05 «Нота Бене» студиясе.
12.00 «Санта Барбара».
13.35 Тинко.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
16.00 «Ноу-хау».
16.30 «Айболит-92». 1 нче кисәк.
17.00 Яңалыклар.
17.15 «Европа—Азия».
18.00 «НАТОдан репортаж».
20.25 «Санта Барбара».
21.15 Хроно.
21.45 «ВКВ».
21.55 Съезд эше турында отчет.
23.00 Хәбәрләр.
23.25 Спорт каруселе.
23.30 Съезд эше турында отчет.

**ҖОМГА**
**4 ДЕКАБРЬ**

**ТАТАРСТАН КАНАЛЫ**

7.00—8.00 «Чулпан». Информацион-музыкаль программа.
18.50 Киносәяхәтчеләр альманахы.
19.00 Татарстан.
19.30 Реклама курьеры.
19.35 «Видеоспорт».
19.50 «Җомга көн кич белән». Альманах.
20.20 Тапшырулар программасы.

**ОСТАНКИНО КАНАЛЫ**

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 «...уналтыга кадәр һәм өлкәнрәкләргә».
10.00 Концерт.
10.10 Мультфильмнар.
10.40 Сәяхәтчеләр клубы.
11.30 «Америка М. Таратута белән».
12.20 «Дустым минем». Нәфис фильм.
15.25 Бридж.
15.50 Бизнес-класс.
16.05 Блокнот.
16.10 Мультфильм.
17.00 Ф. Баксман. Ж.Бизеның «Кармен» темасына скрипка белән фортепиано өчен фантазия.
17.10 Үзәк.
17.50 Пресс-экспресс.
18.00 Яңалыклар.
18.25 «Останкино» тәкъдим итә.
18.50 «Кеше һәм закон».
19.25 «Америка М. Таратута белән».
19.50 Могҗизалар кыры.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 «Монсо үзәнлеге мәетләре». Нәфис фильм.
23.10 «Сәяси бюро».
23.40 «Музобоз».
00.45 «Атна кешесе».
01.00 «Йолдызлы яңгыр».

**«РОССИЯ» КАНАЛЫ**

8.00 Хәбәрләр.
8.20 Эшлекле кешеләр заманы.
9.00 «XX гасыр». Документаль фильм.
10.00 «Алтын шпора».
10.30 «Антон Чеховның җәйге каникуллары».
11.30 «Кропоткинскидагы музыкаль кичәләр».
12.00 «Санта Барбара».
12.50 «Ял».
13.00 «НАТОдан репортаж».
12.50 ТВ-ателье.
13.05 Сагышлы утырмалар.
13.35 Тинко.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
16.00 Телебиржа.
16.30 «Айболит-92». 2 нче кисәк.
17.00 Яңалыклар.
17.15 «Шулай да мин ышанам».
17.45 «М-трест».
18.00 «Чыганаклар».
18.30 «Съезд көндәлеге».
20.25 Нәфис фильм.
22.00 Съезд эше турында отчет.
23.00 Хәбәрләр.
23.25 Спорт каруселе.
23.30 Съезд эше турында отчет.




4. Ревматизм аякта булса, аяк формасындагы капчыклар тегеп каен яфрагы тутырырга. Авыруның аякларын шул капчыкларга тыгып яткырырга. Аяклар бик нык тирләр, мунчадагы кебек. Яфраклар юешләнсә, алмаштырырга кирәк. Бу сеансны берничә тапкыр кабатларга.

5. Халык медицинасын өйрәнүчеләр раславынча, каен бөресеннән ясалган дарулар киң кулланыла.

Бөреләрне суда яки спиртта тотып төнәтмә ясыйлар. Шуның белән уыналар. Кайвакыт тирләү өчен кайнар суда пешереп эчәләр. Каен бөресеннән мазь бик көчле һәм тәэсирле чара булып исәпләнә.

Мазь болай ясала. 700 грамм сыер мае алына. Майны каен бөреләре белән чиратлаштырып балчык чүлмәккә салырга. 1,5 сантиметр май катламына шулкадәре үк бөре җәяргә. Чүлмәк тулганчы шулай кабатларга. Аннары чүлмәкне каплап, камыр белән сылап, 24 сәгатькә мичкә утыртырга. Соңыннан майны сыгып алып 7—8 грамм камфара өстәргә. Майның өстен каплап салкын урында тотарга. Йоклар алдыннан авырткан җирләрне уарга.

6. Ревматизмны кырмыскалар белән дәвалау киң таралган. Берничә ысулын тәкъдим итәбез:

а) кырмыска оясын тулысы (кырмыскалары, йомыркалары, чүбе) белән алырга. Ревматикның авырткан урыннарын марля белән капларга да шушыларны салырга. Кул-аякларны паралич сукканда да кулланырга мөмкин бу чараны.

**АШКАЗАНЫ АВЫРТСА**

**. Ике аш кашыгы ак майны, ике йомырка сарысын, бер чәй калагы бодай онын шул ук күләмдә бал белән кушарга. Көненә берничә мәртәбә бер бал калагы эчәргә.**

⊙ ⊙ ⊙

**Язын каен суы эчү файдалы.**

**Мөхәррир урынбасары Р. З. АЙЗАТУЛЛИН**

**Учредительләр: редакциянең хезмәт коллективы һәм халык депутатларының Октябрь районы Советы.**

**Редакциянең адресы: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. Телефоннар: мөхәррир 2—12—14, 2—22—81; мөхәррир урынбасары һәм Советлар тормышы бүлеге 2—10—44, рус теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—15—63; авыл хуҗалыгы бүлеге 2—10—44; яңалыклар һәм промышленность бүлеге 2—22—51, җаваплы секретарь, хатлар, массалар белән эшләү, радиотапшырулар бүлеге, бухгалтерия һәм реклама бүлеге 2—18—67; фотокорреспондент 2—15—63.**

**Газетаның басылу сыйфаты турында типография директорына түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә: 2-10-54.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Нина ТОЛМАЧЕВА верстка ясады. Наташа ЛУКОЯНОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА. Күләме—1 басма табак.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә. Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.**

**Тираж 3751. Заказ 143.**